| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 18 феврале №4

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

9 статьяның 7 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урам, 105 йорт, Тегермән урамы, 23 йорт, Югары Чыршылы авылы, Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановка авылы, Совет урамы, 13 йорт йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Лениногорск муниипаль районы
« Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Совет рәисе Н.Я.Хәйруллина